Узган ел “Рузаевка тегv фабрикасы” яна инвестор тапты. Тобәк житәкчелеге һәм Мордовия Хокvмәте ярдәме белән предприятие «Легпромресурс» эре холдингнын бер олеше була. Компания 23 елдан артык илнен ин эре нефть-газ компанияләрен махсус кием белән тәэмин итә.
Продукцияне житкерv географиясе Россиянен ботен территориясен колачлый.
“Легпромресурс” шунда ук безнен фабриканы яна заказлар белән тутырган. Бер vк вакытта тегvчеләрнен хезмәт хакы vсеше һәм штатны кинәйтv процессы бара.
Предприятие киләчәккә ышаныч белән карый; ул 5 елга заказлар белән тәэмин ителгән.
Эш урыннары саны арта. Монда һәрвакыт командага яна хезмәткәрләр котәләр. Хәзер заводка 30 тегvче кирәк.
12 январьда Рузаевка шәһәре администрациясе башлыгы Алексей Домнин Рузаевка тегv фабрикасында булды. Ул производствоны карап чыкты һәм эшчеләр белән аралашып, аларнын хезмәт хакы лаеклы булуына инанды. Хәзерге вакытта тегvченен хезмәт хакы 50 мен сумнан ким тvгел.
Шәһәр мэры Алексей Домнин “Рузаевка тегv фабрикасы” директоры Антон Киржаев белән эшкә урнашу һәм яна хезмәткәрләр жәлеп итv мәсьәләләре буенча фикер алышты.
Ул быел 150 эш урынына тагын бер цех тозv һәм уку vзәген жиһазлау планлаштырылуын билгеләп vтте.